# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Яхшы-Бай авыл җирлеге  Мәсгут торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**18 ноябрь 2022 ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгут авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгут авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда катнашучыларның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку рәвешендә укучы студентлардан, өлешчә мобилизациягә чакырылган гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш бер тапкыр бирелә торган түләү, аны 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләде.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:
- ТР Азнакай МР Яхшы-Бай авылында зират коймасын (демонтаж, монтаж, панельләр сатып алу) алмаштыру.

3. Әлеге карарны,  кабул ителгәннән соң 10 кон эчендә, Яхшы-Бай авылы Мәсгут авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм  Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru)  урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авыл җирлеге башлыгы

Д.З. Миннеханов